БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«__25__» __05___ 2020 ел № _184_

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларын раслау турында**

«Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләве шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары, «Татарстан Республикасы дәүләт милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартлары турында» 2020 елның 22 апрелендәге 314 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, 2020 елның 22 апрелендәге 821-р номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп тору шартларын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Балтач муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А. Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2020 елның ___________________
_____ номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
милкендә булган күчемсез мөлкәтне арендалау
шартнамәләре буенча аренда түләвен түләүне кичектереп
тору шартлары

1. 2020 елда күчемсез мөлкәтне файдаланган өчен каралган аренда түләвен түләүне кичектереп торуның әлеге шартлары «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан 2020 елда Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек һәм гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнче, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә вәзгыятьнең начараюы шартларында аеруча зыян күргән, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган Россия икътисады тармакларында эшчәнлек алып баручы оешмалар һәм шәхси эшкуарлар булган арендага алучылар белән төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла (алга таба - аренда шартнамәсе, кичектереп тору).

2. Кичектереп тору, торак биналардан тыш, күчемсез мөлкәткә карата бирелә.

3. Кичектереп тору 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә гадәттән тыш хәлнең югары әзерлек режимы кертелгәннән соң түбәндәге шартларда бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч 2021 елның 1 гыйнварыннан да иртәләмичә һәм 2023 елның 1 гыйнварыннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан да арттырмыйча, күләме аренда шартнамәсе буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләр белән түләнергә тиеш;

б) кичектереп тору Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу вакытына, тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булуы туктатылган көннән алып тиешле чорда аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) арендага алучы тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм вакытларын үтәмәү белән бәйле рәвештә штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яки башка җаваплылык чаралары (шул исәптән

мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кичектерүгә бәйле рәвештә кулланылмыйлар;

г) кичектерүгә бәйле рәвештә арендага бирүче тарафыннан арендага алучы түләргә тиешле өстәмә түләүләрне билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсендә арендага алучы коммуналь хезмәт күрсәтүләрдән файдаланган өчен түләүләрне һәм (яисә) арендага бирелә торган мөлкәтне тотуга чыгымнарны аренда түләвенә кертү каралган булса, Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яисә) мондый чыгымнар тотудан азат ителгән очраклардан тыш, аренда түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектерү бирелми.

4. 3 пунктта каралган кичектереп тору шартлары мондый килешү төзелгән датага карамастан кичектереп тору турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.